**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**2020 елның 13 ноябре** **№13**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында 2019 елның 1 ноябрендәге 211 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Күгеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Күгеш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Күгеш авыл җирлеге Советының 2019 елның 1 ноябрендәге 211 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында " гы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» карар исемендә «һәм сроклары турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» карар преамбуласында «һәм сроклары турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 3 пунктның өченче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:
«- салым түләүче-оешмалар өчен салым түләү, җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасының дүрттән бер өлеше буларак, аванс түләүләре белән башкарыла;".

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк түгел.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1 нче йорт (администрация бинасы), Күгеш авылы, Совет урамы, 17 нче йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Күгеш авыл җирлеге башлыгына йөкләнде.

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе:** **А.А.Гатауллин**